**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «03» мартыннан № 56

Татарстан РеспубликасыЯңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» 2024 елның 26 сентябрендәге 242 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Рәисенең 2025 елның 07 февралендәге 5600-МР номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында азык-төлек продуктларына өстәмә индексация турында һәм Татарстан Республикасында мәктәпкәчә мәгариф оешмаларын финанслауның норматив принцибын гамәлгә ашыру буенча методик ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан РеспубликасыЯңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» 2024 елның 26 сентябрендәге 242 номерлы карарының азык-төлек продуктларына норматив чыгымнар өлешенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карар белән расланган Яңа Чишмә муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарда:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында ашамлыклар өчен чыгымнар нормативы

| Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының эш сәгатьләре саны | Туклану продуктларына чыгымнар нормативы, 1 көнгә сумнарда/ бер тәрбияләнүчегә | | | |
|---|---|---|---|---|
| | гомуми үсеш төркемнәре (шул исәптән төрле яшьтәге) | | шифаханә (санатор) төркемнәре | |
| | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып белем бирү процессы туктатылганчы | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып белем бирү процессы туктатылганчы |
| 3-4 | 33,88 | 42,65 | | |
| 5-6 | 81,28 | 102,39 | | |
| 7-12 | 135,49 | 170,64 | 175,78 | 234,39 |
| 24 | 169,34 | 210,66 | 219,73 | 289,36 |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов